КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 февраль г.Казань № 102

Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру документациясен әзерләү турында

«Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, юл хәрәкәтен оештыруның расланган комплекслы схемаларына үзгәрешләрне эшләү, органнар һәм оешмалар белән килештерү һәм раслау тәртибе;

алар белән муниципаль район, шәһәр округы яисә шәһәр җирлеге йә аларның өлешләре территориясе өчен, шулай ук уртак чиге булган берничә муниципаль район, шәһәр округлары яисә шәһәр җирлекләре территорияләре өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, юл хәрәкәтен оештыруның расланган мондый комплекслы схемаларына үзгәрешләрне килештерергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеге;

Төбәк, муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен, хосусый автомобиль юллары өчен юл хәрәкәтен оештыру проектларын, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне әзерләү, органнар һәм оешмалар белән килештерү һәм раслау тәртибе;

төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары яисә аларның участоклары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектларын, юл хәрәкәтен оештыруның әлеге проектларына үзгәрешләрне килештерүне гамәлгә ашыручы органнар һәм оешмалар исемлеге.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары яисә аларның участоклары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектларын килештерүне гамәлгә ашыручы органнар һәм оешмалар исемлеген һәм Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе яисә аларның өлешләре өчен, шулай ук уртак чикләре булган берничә муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемалары килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген раслау турында» 2019 ел, 6 март, 161 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 20 февраль, 102 нче
карары белән расланды

Юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, юл хәрәкәтен оештыруның расланган комплекслы схемаларына үзгәрешләрне эшләү, органнар һәм оешмалар белән килештерү һәм раслау тәртибе

1. Әлеге Юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, юл хәрәкәтен оештыруның расланган комплекслы схемаларына үзгәрешләрне эшләү, органнар һәм оешмалар белән килештерү һәм раслау тәртибе «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Комплексы схемаларны эшләү, Федераль законның 17 статьясындагы 9 өлешенең 1, 2 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән органнар һәм оешмалар (алга таба – Комплексы схемаларны карый торган органнар һәм оешмалар) белән килештерү һәм раслау тәртибен билгели.

2. Комплексы схемалар эшләүне җирле үзидарә органнары тәэмин итә.

3. Җирле үзидарә органы яисә органнары (алга таба - Комплексы схеманы эшләүче) Комплексы схемаларны караучы органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен Комплесы схеманы кәгазьдә яисә электрон документ рәвешендә озату хаты белән килештерү өчен тапшыралар.

4. Комплексы схеманы карый торган органнар һәм оешмалар тарафыннан Комплексы схеманы карау срогы килештерүгә кергән көннән алып 30 календарь көннән артык була алмый.

5. Комплексы схеманы карау йомгаклары буенча Комплексы схемаларны караучы органнар һәм оешмалар Комплексы схеманы эшләүчегә язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә җавап җибәрә.

6. Җавапта Комплексы схеманы килештерү турында яисә, искәрмәләрне күрсәтеп, Комплексы схеманы килештерүдән баш тарту турында мәгълүмат булырга тиеш.

Комплексы схемаларны карый торган органнардан һәм оешмалардан әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән вакытта җаваплар булмаган очракта, Комплексы схема Комплексы схемаларны карый торган күрсәтелгән органнар һәм оешмалар белән килештерелгән дип санала.

7. Комплексы схеманы килештерүдән баш тарту өчен түбәндәге таләпләрне бозу нигез була:

1) Федераль закон нигезендә чыгарылган норматив хокукый актлар;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 4 ноябрендәге 2438-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе территориясендә юл

хәрәкәтен оештырганда аларны мәҗбүри куллану юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итә торган стандартлаштыру буенча документлар исемлегенә кертелгән юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә стандартлаштыру документлары,

8. Комплекслы схеманы килештерүдән баш тарту турындагы мәгълүматны үз эченә алган җавапта таләпләре Комплекслы схеманы эшләүче тарафыннан бозылган әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән норматив хокукый актларның һәм (яисә) стандартлаштыру документларының структур берәмлеген (статьны, өлешне, пунктны) күрсәтергә кирәк.

Комплекслы схеманы эшләүче, Комплекслы схеманы килештерүдән баш тарту турында мәгълүмат булган җавап алганнан соң, Комплекслы схеманы караучы органнарга һәм оешмаларга кабат Комплекслы схеманы тапшырырга хокуклы.

9. Комплекслы схеманы Комплекслы схеманы караучы органнар һәм оешмалар җавапларындагы кисәтүләрне бетермичә яки кисәтүләрне исәпкә алу мөмкин булмау турында дәлилләнгән позициядән башка кабат килештерүгә бирү рөхсәт ителми.

10. Комплекслы схема Комплекслы схемаларны карый торган барлык органнар һәм оешмалар килештерүләрен алган көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча кәгазьдә - «РАСЛАНДЫ» грифы белән (куштырнакларсыз) Комплекслы схеманың титул кәгазенең өске өлешендә җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан, мондый затның вазыйфасы исеме, аның имзасы, инициаллары, фамилиясе һәм раслау датасы күрсәтелеп, яисә электрон документ рәвешендә - көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кую һәм электрон имза турында тамга кую юлы белән җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан, мондый затның вазыйфасы исеме, аның инициаллары, фамилиясе һәм раслану датасы күрсәтелеп, яки муниципаль хокукый акт белән расланырга тиеш.

11. Расланган Комплекслы схемаларга үзгәрешләр кертү федераль законда билгеләнгән очракларда гамәлгә ашырыла. Расланган Комплекслы схемаларга үзгәрешләрне килештерү һәм раслау әлеге Тәртипнең 3 - 10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.